СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2021 г. Заинск № 54

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 472-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советының 2013 елның 24 маендагы 124 номерлы карары белән расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Р-1 зонасын (гомуми файдаланудагы коелган орлыктан тишелгән үсемлекле территорияне һәм ачык яр буе территориясен) ОД1 зонасына үзгәртү өлешендә (16:19:120101: 256 кадастр номерлы җир кишәрлеге, күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона), кушымта нигезендә (теркәлә) үзгәреш кертергә.
2. Район Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертелгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүматны территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.
4. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Советының законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г.Кәримов**

Зәй муниципаль районы
Советының
2021 елның 20 мае
54 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2016 елның 15 ноябрендәге 171 номерлы карары нигезендә расланган үзгәрешләр белән Сәвәләй авыл җирлеге Советының 2013 елның 24 маендагы 124 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарына**

**ачыклык кертү язмасы**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авылы җирлегенең Сәвәләй авылы территориясендә шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына түбәндәге үзгәреш кертелә:

- 16:19:120101:256 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан Р-1 зонасы (гомуми файдаланудагы коелган орлыктан тишелгән үсемлекле территорияне һәм ачык яр буе территориясен) территориясен ОД1 - күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонасына үзгәртү карала.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Сәвәләй авылы территориясенең шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләр нигезендә, чикләүләрнең гамәлдә булу зоналары чикләрен проект белән үзгәртү күздә тотылмый;

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең территориядән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең аерым шартлары булган зоналар чикләре картасына һәм текст өлешенә үзгәрешләр кертелми.

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү таблицасы**

| Җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертелә торган объектның исеме | Кертелә торган үзгәрешләр | Үзгәрешләр кертелә торган материалларга сылтама |
|---|---|---|
| 16:19:120101:256 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнашкан территория | Р-1 зонасын (гомуми файдаланудагы коелган орлыктан тишелгән үсемлекле территория һәм ачык яр буе территориясе) ОД1 - күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зонасына үзгәртү | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлегенең Сәвәләй авылы территориясендә шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы |